ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

1 июль, 2024 ел № 34/5

Шәһәр Советының 2022 елның 26 декабрендәге 19/4 номерлы Карары белән расланган акцияләрнең йөз проценты (өлеше) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенә караган муниципаль унитар предприятиеләр һәм хуҗалык җәмгыятьләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының, баш бухгалтерларының хезмәте өчен түләү шартлары һәм тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 145 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2022 елның 26 декабрендәге 19/4 номерлы Карары белән кабул ителгән акцияләрнең йөз проценты (өлеше) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенә караган муниципаль унитар предприятиеләр һәм хуҗалык җәмгыятьләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының, баш бухгалтерларының хезмәте өчен түләү шартлары һәм тәртибе турында нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2023 елның 29 июнендәге 25/6, 2023 елның 25 октябрендәге 27/6, 2024 елның 4 мартындагы 32/5 номерлы Карарлары редакциясендә), 2 таблицаның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

| № т/б | Эшчәнлек төре | Оешма хезмәткәрләренең еллык уртача исемлек саны | Эшчәнлекнең төп төре буенча хезмәткәрнең вазыйфаи окладын арттыру |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | Җир өсте шәһәр электр транспорты эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма | 600 кадәр | 2,93 |
| | | 601 һәм аннан артыграк | 3,0 |

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев